| | |
|---|---|
| СОВЕТ<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО<br>ОБРАЗОВАНИЯ<br>«УРМЫШЛИНСКОЕ СЕЛЬСКОЕ<br>ПОСЕЛЕНИЕ»<br>ЛЕНИНОГОРСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЛЕНИНОГОРСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>«УРМЫШЛЫ<br>АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»<br>МУНИЦИПАЛЬ<br>БЕРӘМЛЕГЕ<br>СОВЕТЫ |

РЕШЕНИЯ КАРАР

2023 елның 10 апреле № 14

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Урмышлы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының «Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районыннан җирле әһәмияттәге аерым мәсьәләләрне хәл итү вәкаләтләренең бер өлешен гамәлгә ашыруны кабул итү турында» 2022 елның 19 декабрендәге 29 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясының 3 өлеше, 15 статьясы, Лениногорск муниципаль районы «Урмышлы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Урмышлы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советы КАРАР БИРДЕ:

1. Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Урмышлы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының «Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районыннан җирле әһәмияттәге аерым мәсьәләләрне хәл итү вәкаләтләренең бер өлешен гамәлгә ашыруны кабул итү турында»2022 елның 19 декабрендәге 29 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

карарның исемендә «Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районыннан» сүзләрен төшереп калдырырга;

карарның 1, 2 пунктларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.Татарстан Республикасы «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Советыннан Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Урмышлы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Җирдән файдалану һәм төзү кагыйдәләрен эшләү, үзгәреш кертү өлешендә җирле әһәмияттәге аерым мәсьәләләрне хәл итү вәкаләтләренең бер өлешен кабул итәргә.

2.Татарстан Республикасы «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Советы белән әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән вәкаләтләрне тапшыру турында килешүне төзергә.»;

3 пунктта «вәкиллекле орган» сүзләрен «Совет» сүзенә алмаштырырга.

2.Әлеге карарны Татарстан Республикасы, Лениногорск районы, Урмышлы авылы, Үзәк урам, 4, Яңа Елховой авылы, Родничная урамы, 22, Бохар авылы, Авангард урамы, 23 йорт адресы буенча урнашкан мәгълүмати стендларда халыкка җиткерергә, Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында (http://leninogorsk.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru/) бастырып чыгарырга.http://pravo.tatarstan.ru/

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплыгымда калдырам.

Лениногорск муниципаль районы
«Урмышлы авыл җирлеге»
муниципаль берәмлеге башлыгы,
Совет рәисе А.Ф.Хәбибуллин